
БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDREN'S MAGAZINE

№7.2016

# Салават күпере

0+




ISSN 0868-4545




## 2016 – ТАТАРСТАНДА СУ САКЛАУ ЗОНАЛАРЫ ЕЛЫ

«SK» КАЛЕНДАРЬ

# ИЮЛЬ

| ДҮШӘМБЕ | СИШӘМБЕ | ЧӘРШӘМБЕ | ПӘНҖЕШӘМБЕ | ҖОМГА | ШИМБӘ | ЯКШӘМБЕ |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | | | | 1 Диңгез һәм елга флоты хезмәткәрләре көне | 2 НЛО көне | 3 ЮХИДИ көне |
| 4 Шатлык көне | 5 Әби-бабайга кайту көне | 6 Үбүләр көне | 7 Диңгез көне | 8 Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне | 9 Беренче телефон компаниясе көне | 10 Россия почтасы көне |
| 11 Бөтендөнья шоколад көне | 12 «Салават күпере» уеннарын уйнау | 13 Балыкчылар көне | 14 Китап уку көне | 15 Дөрес туклану көне | 16 Авокадо көне | 17 Металлурглар көне |
| 18 Зиннур Хөсниярның юбилее | 19 Урамда уйнау көне | 20 Шахмат көне | 21 Җырлау көне | 22 Көтелмәгән сөенечләр көне | 23 Дельфиннар көне | 24 Серләр көне |
| 25 Бәхет көне | 26 Парашютчылар көне | 27 Бутерброд туган көн | 28 PR белгечләре көне | 29 Халыкара тигрлар көне | 30 Йокы көне | 31 Хәрби-диңгез флоты көне |

© «Салават купере», 2016 ел.

**Безнең VKontakte битенә «Салават күпере» журналы белән төшкән фотоңны куй һәм табыш җый!**

## МИН «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н УКЫЙМ!




Азамат, 5 яшь, Айзилә, 4 яшь, Казан.



Алия, 8 яшь, Саба.



Илнур, 6 яшь, Данил, 5 яшь, Ильяр, 1 яшь, Яшел Үзән.



Ильдан, 1 яшь, Аделина, 3 яшь, Актаныш.



Язгөл, 7 яшь, Чирмешән.



Ләйлә, 2 яшь, Чирмешән.

Зиннур ХӨСНИЯР

# ИДЕЛ БУЙЛАП СӘЯХӘТ



*Хикәят*

«Балык сөйләшә белми бит!» – диярсез инде сез. Аннары «Алтын балык» әкиятен искә төшерерсез. Һәм, әкиятче бабай дип, миннән көләрсез дә әле! Миңа ышанмасагыз, әнә Булат исемле малайдан сорагыз! Сөйләшә белә торган көмеш балыкны мин түгел, ул тотты! «Алтын балык»тагы тылсымчы балык, чыннан да, әкияттә генә яши торгандыр ул. Ә менә кайсыгызның көмеш балык турында әкият укыганы бар? Юк бит! Чөнки андый әкият юк. Дөресрәге, моңа кадәр юк иде...

Әтисе Булатны Идел елгасына балыкка алып барды. Әти кеше зур-зур балыклар тотты ул көнне, ә Булатның кармагына баш бармак чаклы гына бер балык эләкте. Кеше-кара күргәнче дип, ул балыкны елгага кире җибәрергә дә уйлаган иде. Ләкин балык аның белән сөйләшә башламасынмы?! «Җибәрмә! Кире җибәрмә!» – диде ул Булатка, ялварып. – Чуртан малае бар анда! Шуннан котылыр өчен синең кармакка эләктем дә инде мин!» – диде балык кеше теле белән! Булат аптыравыннан лып итеп комга утырды, балык тоткан кулын ачып карады, ул һаман сөйләшә иде әле: «Алып кайт мине үзең белән! Үкенмәссең!».



Алтын балык тоттым ахрысы дип уйлады малай. Әкияттәге кебек! Малай балыкны тиз генә сулы савытка салды һәм күзәтә башлады. Үзе бер дә алтынга охшамаган бу! Канатлары гына көмеш төсендә. Менә берзаман балыкның бар гәүдәсе көмешкә әверелде. Ул ялт-йолт килеп тора иде.

Булат балыкны үзе белән өенә алып кайтты һәм аквариумга җибәрде. Хәзер малайның тагын бер дусты – көмеш балыгы бар...

# ЗӨЯ

ЗӨЯ ЕЛГАСЫ (РЕКА СВИЯГА)

Иделнең уң як кушылдыгы
Бассейны – Идел
Елга башы – Идел буе калкулыгы
Елга тамагы – Идел елгасы
Озынлыгы – 375 км
Бассейн мәйданы – 16700 км$^2$
Киңлеге – 5-40 м
Тирәнлеге – 0,3-4,0 м
Агым тизлеге – 0,1-1 м/с
Төп кушылдыклары – Тимерчән, Чынлы, Карлы, Бола, Үләмә, Коры Гөбенә, Әрә, Тоша, Бәрле һ.б.



– Теге чуртан малаеннан ник качырга булдың син? – дип сорады Булат, көмеш балык белән танышу мизгелен исенә төшереп.

– Әй, туйдырды инде ул мактанчык чуртан! «Мин бөтен Татарстан елгалары буйлап йөздем, бар сулыкларны беләм», – дип мактана бит.

– Ник, әйдә, без дә йөзәбез!

– Ә ничек? Мин – балык, су асты дөньясы – минем мохитем. Ә син нишләрсең?

– Мин сине коткардым! Димәк, син минем өч теләгемне үтәргә тиеш. Беренче теләгем – синең кебек балык булу!

– Теләгең кабул! Якты ут, саф һава, чиста су – тормышның терәге бу! Булат балык булсын!

Шатлыгыннан Булатның битеннән күз яшьләре тәгәрәде. Дөньяда чып-чын тылсым бар икән! Шул мизгелдә әле генә җиде яшен тутырган Булат исемле малай кечкенә генә бер балык малаена әйләнде дә яңа дусты янына аквариумга чумды. Тылсым-тылсым булсын инде: шул аквариумнан алар Зөя елгасына килеп чыктылар.

– Кара-кара, монда нинди генә балык юк! – дип шаккатты Булат исемле балык.

– Әйе, Зөядә чуртан, алабуга, судак, кәрәкә, корбан балыгы, кызылканат, җәен, сазан кебек балыкларны очратып була. Шулай ук Зөя елгасы – Татарстан Республикасында Иделнең иң беренче кушылдыгы.

– Ә бу нинди искиткеч утрау?

– Идел белән Зөя кушылган җирдә Зөя утрау-шәһәре урнашкан. Күптән түгел Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев башлангычы белән ул «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» итеп үзгәртелде һәм хәзер республикабызда матур ял итү урыннарының берсе булып тора.



**Казан ханлыгын басып алыр алдыннан Явыз Иван Мышкино шәһәреннән Зөя елгасы буена агач кремль күчереп куйдыра. Кремльнең һәр бүрәнәсен билгеләп, Идел буйлап агызалар һәм Зөя елгасы буенда җыя баралар. 24 көн эчендә 75 мең кеше бүрәнәләрдән ныгытма төзи. Аңа Свияжск, ягъни Зөя дип исем бирәләр.**

| 2016 | ИЮЛЬ | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| дүшәмбе | | 4 | 11 | 18 | 25 |
| сишәмбе | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| чәршәмбе | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| пәнҗешәмбе | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| җомга | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| шимбә | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| якшәмбе | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |

# КАЗАНСУ



**КАЗАНСУ, КАЗАН ЕЛГАСЫ (КАЗАНКА)**

**Иделнең сул кушылдыгы**
**Елга башы – Арча районының Казанбаш авылы янында**
**Елга тамагы – Куйбышев сусаклагычы**
**Озынлыгы – 140 км**
**Бассейн мәйданы – 2600 км$^2$**
**Тирәнлеге – 0,5-1,5 м**
**Киңлеге – 20-25 м**
**Агым тизлеге – 0,1-0,3 м/с**
**Төп кушылдыклары – Ия, Аты, Кешмәш, Верезинка, Каменка һ.б.**



Балыклар Идел елгасы буйлап йөзүләрен дәвам итте. Сул якта Аракчино бистәсе, уң як яр буенда Югары Осланны күреп уздылар. Аларны Казансу елгасы агымы Татарстан башкаласына таба алып китте.

– Мин Казансу елгасын беләм! Чөнки Казансу ярында, Казан шәһәренең үзәк өлешендә, тарихи һәйкәл – Кремль балкып тора. Безнең анда сыйныф белән экскурсиягә барганыбыз бар! – диде Булат-балык. – Казансу елгасы шул Казан шәһәре буйлап акканга күрә шулай аталадыр инде...

– Бәлки шулайдыр... Шәһәрнең исеме турында төрле риваятьләр бар. Хан хезмәтчесе елгага алтын казан төшереп җибәргән имеш. Шуннан суны да, шәһәрне дә Казан дигәннәр. Икенчеләре болай ди: Казансу елгасы урыны-урыны белән казан сыман тирән чокырлы булган. Шуңа күрә шәһәрне Казан дип атаганнар. Шәһәр тау астында урнашканга, Казан дип аталган диючеләр дә бар. Тарихчылар арасында уртак фикер әлегә юк.

– Менә үсәм дә галим булам! Аннары тарихта бернинди табышмак-сораулар калдырмам!

– Киттек, әйдә, мин сиңа Казан ханлыгының серле хәзинәсен күрсәтәм!

– Нинди хәзинә? Алтынмы? Судамы?

– Моның өчен безгә Болак дип исемләнгән ясалма сулык аша Кабан күленә юл тотарга кирәк. Болак Казансу елгасы белән Кабан күлен тоташтыра. Казан ханлыгы вакытында әлеге канал буйлап сәүдә көймәләре уза, шуңа елга юлы тагын да тирәнәя, яр буйлап су тегермәннәре, мунчалар төзиләр.

– Болакны да күргәнем бар! Анда искиткеч фонтаннар узып баручыларның кәефен күтәрә!



**Куйбышев сусаклагычы төзелгәнче XX гасыр урталарында Казансу елгасы күпкә таррак була. Шунысы кызык, хәзерге дамба тирәсендә элек күпер һәм йортлар булган.**

**Казансу елгасы рәсми рәвештә Казанның беренче урында торучы табигый һәйкәле санала. Аның аша башкалабызның меңъеллыгына төзелгән «Миллениум» күпере уза.**

| 2016 | АВГУСТ | | | | |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| дүшәмбе | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| сишәмбе | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| чәршәмбе | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| пәнҗешәмбе | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| җомга | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| шимбә | 6 | 13 | 20 | 27 | |
| якшәмбе | 7 | 14 | 21 | 28 | |

# КАБАН



КАБАН КҮЛЕ (ОЗЕРО КАБАН)

Татарстанда иң зур күл булып санала
Өч өлештән тора: Бирге Кабан, Аргы Кабан һәм Ерак Кабан
Озынлыгы – 6,5 км
Мәйданы – 1,86 км$^2$
Киңлеге – 0,35 км
Иң зур тирәнлек – 12,5 м
Гомуми су күләме – 11,8 млн.м$^3$

photokzn.ru

Менә Булат һәм Көмеш балык Кабан күленә йөзеп керделәр. Анда аларны тантаналы рәвештә балыклар һәм күл бакасы Бакаулла каршы алды. Булатның аның белән бик тә күрешәсе килә иде. Кабан күле төбендәге серле хәзинә турында белә торгандыр ул.

Бакаулла сүзен болай дип башлады:

– Мин сезнең озын сәяхәткә чыгуыгыз хакында ишеттем. Чебен дуслар хәбәр итте. Кабан күле төбендә чынлап та хәзинә бар! Анда алтын белән тулган көмеш сандыклар да бик күп!

Бу сүзләрдән соң Булатның маңгаена тамчы-тамчы тир бәреп чыкты! Димәк, дөрес икән! Димәк, Кабан күле төбендә чынлап та алтын-мәрҗәннәр бар!

– Каян килде сезгә мондый байлык? Әллә сез каракмы, Бакаулла әфәнде? – дип сорарга ашыкты Булат.

– Юк ла. Байлык минеке түгел. Мин монда бары тик экскурсияләр алып баручы, балыкларга Казан ханлыгы байлыкларын күрсәтәм. Явыз Иван гаскәрләре шәһәргә якынлашкач, бөтен ханлыкның байлыгы җыеп Кабан күле төбенә төшерелә. Казна өч өлештән тора: беренче өлеше – алтын һәм көмеш коелмалары, кыйммәтле таш кисәкләре, алтын тәңкәләр. Икенчесе – акча: гарәп, төрек, мисыр, аурупа, урыс тәңкәләре. Өченче өлеше – хәзинәлек. Аның авырлыгы берничә тонна.

– Булат, ничек уйлыйсың, теге чуртан малаена Кабан күле байлыкларын күрдем дисәм, ышаныр микән? – дип борчыла башлады Көмеш балык.

– Әлбәттә, юк. Андыйлар Татарстанның иң зур күле – Кабан күлендә булдым дигәнгә дә ышанмас.

**Борынгы Казан ханлыгы риваятьләренә караганда, Кабан күле исемен ул вакытларда аның тирәсендәге имәнлекләрдә бик күп булган кабан дуңгызларына бәйле алган.**

**Кабан күленең күпләрне кызыксындырган сере – аның төбендә хан байлыклары булу. Ышануларга караганда, Явыз Иван гаскәрләре шәһәргә якынлашкач, бөтен ханлыкның байлыгы җыеп Кабан күле төбенә төшерелә. Ләкин бүгенге көнгә кадәр аларның табылганы юк.**



| 2016 | СЕНТЯБРЬ | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| дүшәмбе | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| сишәмбе | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| чәршәмбе | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| пәнҗешәмбе | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| җомга | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| шимбә | 3 | 10 | 17 | 24 | |
| якшәмбе | 4 | 11 | 18 | 25 | |


КУЙБЫШЕВ
СУСАКЛАГЫЧЫ
КУЙБЫШЕВ СУСАКЛАГЫЧЫ (КУЙБЫШЕВСКОЕ ВОДОХРАНИЛИЩЕ)
Идел елгасының урта өлешендә, Сембер һәм Самара өлкәләрендә, бер өлеше (51%) Татарстанда урнашкан
Озынлыгы – 500 км
Мәйданы – 6,45 мең км$^2$
Күләме – 58 км$^3$
Иң зур тирәнлек – 41 м
Уртача тирәнлек – 8 м
Яр сызыгы озынлыгы – 2604 км
Тутыру елы – 1957
Төп кушылдыклары – Илләт, Зөя, Казансу, Чулман, Олы Чирмешән һ.б.

– Кара, кара, монда күпме авыл бар!

– Әйе, Идел елгасы ярларында күп кенә торак пунктлар урнашкан, чөнки кешеләр электән-электән тормышларын сулыклар булган җирдә башлап җибәргән. Идел аларны су белән тәэмин итеп, авыл хуҗалыгы, мал асрау, көн күрү өчен яшәү чыганагы булып торган.

– Көмеш балык, ә менә бу нинди зур күл?

– Булат, бу күл түгел. Без Куйбышев сусаклагычында. Иделдә барлыгы тугыз сусаклагыч бар, Куйбышев сусаклагычы – аларның иң зурысы. Ул Ульянов һәм Самара өлкәләре, Татарстан, Мари һәм Чуаш Республикалары территорияләрендә урнашкан.

– Ә ул ничек барлыкка килгән?

– Ул 1953 елда Иделдә ГЭС төзегәндә Ставрополь (хәзерге Тольятти) шәһәре янында Жигули таулары районында Иделдә плотина кору нәтиҗәсендә барлыкка килгән. 1955-1957 елларда су белән тутырылган.


– Аны кешеләр үзләре тутырамы? Ничек инде мондый зур сулык ясап булсын, ышанмыйм!

– Куйбышев сусаклагычына йөздән артык елга: Нократ, Мишә, Зөя, Казансу, Зәй, Чишмә, Бөрсет, Актай, Бизнә һәм Идел бассейнында иң күп сулы елга – Чулман коя.

Куйбышев сусаклагычы – кешеләргә бик күп файда китерүче сулык. Аны энергетика, суднолар йөртү, су басулар белән көрәш, су белән тәэмин итү, сугару, балык хуҗалыгы һ.б. эшләрдә кулланалар.

– Монда балыклар да төрле-төрле. Әнә корбан балыгы, судак, чуртан, чөгә балыгы, җәен, чабак, налим, кәлчәк йөзеп йөри.

– Хәзер без синең белән Чулман култыгы аша бик зур Чулман елгасына юл тотарбыз.



Куйбышев сусаклагычы Идел өстеннән 600 километрга сузылып Чувашия чигенә, ә Чулман буйлап Нократ елгасы тамагына кадәр диярлек җитә.

Куйбышев сусаклагычы ярлары буенда Казан, Ульяновск, Чистай, Тольятти кебек зур һәм башка кечерәк шәһәрләр, бистәләр, авыллар урнашкан.

| 2016 | ОКТЯБРЬ | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| дүшәмбе | | 3 | 10 | 17 | 24/31 |
| сишәмбе | | 4 | 11 | 18 | 25 |
| чәршәмбе | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| пәнҗешәмбе | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| җомга | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| шимбә | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| якшәмбе | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |

# ЧУЛМАН

ЧУЛМАН ЕЛГАСЫ (РЕКА КАМА)

Киров, Пермь өлкәләрендә, Удмуртия, Башкортстан һәм Татарстанда урнашкан
Идел елгасының сул як кушылдыгы
Татарстан Республикасының икенче зур елгасы
Елга башы – Югары Чулман калкулыгы
Биеклеге – 300 м
Елга тамагы – Куйбышев сусаклагычы
Биеклеге – 36 м
Озынлыгы – 1805 км
Бассейн мәйданы – 507 мең $км^2$
Су чыгымы күләме – 3800$м^3/с$
Елганың авышлыгы – 0,11 м/км
Төп кушылдыклары – Вишера, Мулянка, Чусовая, Агыйдел, Иж, Ык, Туйма, Чишмә, Зәй, Нократ, Мишә һ.б.



– Көмеш балык, минем икенче теләгем бар!
– Ә-ә, әнине сагындым димәкче буласыңмы?
– Әлбәттә. Ләкин өйгә кайтканчы теге мактанчык чуртан малае белән сөйләшеп аласы иде.
– Ярар, теләгең кабул! Якты ут, саф һава, чиста су – тормышның терәге бу! Чуртан малае биредә пәйда булсын!
– Эһем-эһем, кайда мин? – дия-дия, берзаман чуртан малае йөзеп килде. Булат масайган, үзсүзле, мактанчык балык күрермен дип уйлаган иде. Ә аның каршында калган балыклардан бер җире белән дә аерылып тормаган гап-гади чуртан пәйда булды.
– Күптән танышасы килә иде инде синең белән, Чуртан! Көмеш балык сине бик акыллы, өлгер балык дип сөйли. Йәле, кайсыгыз мине Чулман елгасы буенча сәяхәткә алып бара? Кемнең белемнәре тирәнрәк, сөйләве кызыграк, канатлары тизрәк икән?!
Көмеш балык та, Чуртан малае да бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сөйләп киттеләр.
– Чулман елгасы – Идел елгасының сул як кушылдыгы.
– Чулман сүзе удмурт телендә «елга, зур елга» дигән мәгънәне белдерә.
– Ә минем Чулмандагы өч сусаклагыч буенча да йөзгәнем бар: Кама, Воткинск һәм Түбән Кама сусаклагычлары ул, – дип мактанып алды Чуртан малае.
Көмеш балыкның да артта каласы килми:
– Ә мин! Мин...! – дип, ул тотлыга ук башлады.
– Булды! Җитте! Тынычланыгыз! Бәхәсегезне күптән туктатырга вакыт! Минем икегез белән дә дус буласым килә...
Көмеш балык белән Чуртан малае бер мәл тынып калдылар. Аннары гаепле кыяфәт белән бер-берсенә канатларын бирештеләр...

**Чулман Иделдән борынгырак. Бозлану чорына кадәр Чулман Каспий диңгезенә койган, Идел Дон елгасының кушылдыгы була. Бозлык чоры Көньяк Аурупа елгалар челтәрен үзгәртә: Югары Идел Чулманга коя башлый, Чулманның бер өлеше булган Түбән Идел бүген дә Чулман үзәненең дәвамы булып тора.**
**Димәк, Каспий диңгезенә Идел түгел, Чулман коя. Ләкин, тарихи факторларны исәпкә алып, Чулман Иделгә коя дип кабул ителгән.**

| 2016 | НОЯБРЬ | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| дүшәмбе | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| сишәмбе | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| чәршәмбе | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| пәнҗешәмбе | 3 | 10 | 17 | 24 | |
| җомга | 4 | 11 | 18 | 25 | |
| шимбә | 5 | 12 | 19 | 26 | |
| якшәмбе | 6 | 13 | 20 | 27 | |

# НОКРАТ

НОКРАТ ЕЛГАСЫ (РЕКА ВЯТКА)

Чулманның иң зур уң кушылдыгы
Елга башы – Югары Чулман калкулыгы
Елга тамагы – Чулман елгасы
Озынлыгы – 1314 км
Бассейн мәйданы – 129 мең км$^2$
Су чыгымы күләме – 890 м$^3$/с
Төп кушылдыклары – Агыйдел, Кобра, Шушма, Бөр, Ошторма, Любянка, Нурминкә, Шыя һ.б.



meganbolov.ru

– Газиз абый, сәлам! Ни хәлегез бар? – дип кычкырды Булат, Нократ елгасы буенда басып торган әтисенең күптәнге дустын күреп. Ә Газиз абый аны ишетмәде, ул бары каядыр уйнашып-сикерешеп йөзгән балыкларны күзәтеп елмая иде. «Балыклар телен кешеләр аңламый бит! Хәтта балыклар аваз чыгара алмый дип уйлый адәм затлары!» – дигән фикерләр Булатның кәефен төшерде.

Ул вакытта дуслар Мамадыш шәһәреннән ерак булмаган Нократ елгасы буенча йөзә иде.

Көмеш балык Булатның төшенкелеккә бирелгәнен сизеп алды һәм сүз кушты:

– Булат, берничә мизгелдән без Татарстан Республикасы территориясен узып, Киров өлкәсендә булачакбыз. Нократ буенча йөзеп Россиянең башка матур шәһәрләрен дә күрәчәкбез.


– Әйбәт фикер, Көмеш-дус! Ләкин мин сезне Каспий диңгезенә туганнарым янына кунакка чакырам! Тиздән абый өйләнә дигән хәбәр килде, туйда кунак булырбыз! – дип сүзгә кушылды Чуртан малае.

– Юк, дуслар! Сезнең ярдәмегез белән мин чын балык тормышы белән яшәп карадым. Татарстаныбызның бай сулыкларында сәяхәт итеп, онытылмас хатирәләр җыйдым. Әмма әтиәниемне, дуслар-туганнарымны сагындым. Минем өченче теләгем – кабат кеше булу!

Көмеш балык күңелсезләнеп кенә:

– Теләгең кабул! Якты ут, саф һава, чиста су – тормышның терәге бу! Булат кабат кеше булып өенә әйләнеп кайтсын! – диде.

Чуртан малае һәм Көмеш балык Идел елгасы буйлап, туйда нинди тәмле әйберләр булуы турында сөйләшә-сөйләшә, Каспий диңгезенә таба йөзеп китте...




**Нократ Россиянең Аурупа өлешендә урнашкан һәм Киров өлкәсенең төп елгасы булып тора. Аның ярларында төбәкнең зур шәһәрләре урнашкан.**


**Нократ буйлары бик матур, ямьле. Бәлки Киров шәһәрендә балачагы һәм яшьлеге узган язучы Александр Гринны да бу якларның табигате мәшһүр «Ал җилкәннәр» әсәрен язарга этәргәндер.**

| 2016 | ДЕКАБРЬ | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| дүшәмбе | | 5 | 12 | 19 | 26 |
| сишәмбе | | 6 | 13 | 20 | 27 |
| чәршәмбе | | 7 | 14 | 21 | 28 |
| пәнҗешәмбе | 1 | 8 | 15 | 22 | 29 |
| җомга | 2 | 9 | 16 | 23 | 30 |
| шимбә | 3 | 10 | 17 | 24 | 31 |
| якшәмбе | 4 | 11 | 18 | 25 | |

РӘСЕМНӘРНЕ ЯСАП БЕТЕР ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТӨСКӘ БУЯ.



СУ ЮЛЫ ТРАНСПОРТЫН ТҮГӘРӘК ЭЧЕНӘ АЛ.





Җаваплар salavatkupere.com сайтында.

SKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORD

Вятка (татарча)

Түбән Кама аша агучы елга

Шәһәр һәм елга исеме

Көчле су агымы

Куйбышев ... чы

Казандагы иң зур күл

Җир-су хайваны (астан-өскә)

«Язгы ташу» җырының авторы Рәдиф...

...м-төкәм

Зәя елгасы кушылдыгы

(татарча)

Иң тирән күл

Балыклар нәрсә белән туклана?

Татарстанда иң зур елгаларның берсе

Балыкка йөзү өчен кирәк

Кама (татарча)

Татарстандагы елга

Авыл исеме дә, елга да

«...Текла, извивалась, блестела» шигыре авторы

Язын елгада боз китү

... - яшәү чыганагы

Су төбе – кысла яшәгән...

Диңгез козгыны (русча)

Казан өязендәге елга



SKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORD
















# Мәлика Гыйниятуллина

Мин – Гыйниятуллина Мәлика, Яр Чаллы кызы. Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназиянең 1 нче сыйныфын тәмамладым. 5 яшьтән бирле «Чишмә» Халыклар дуслыгы йортының «Сарасвати» студиясендә бию белән шөгыльләнәм. Һинд биюләрен биеп, студия кызларыбыз белән күп тапкыр лауреат булдык. Шулай ук мин чигәм, җырлыйм һәм тырышып укыйм.

Яраткан шөгылең булу – зур бәхет икән ул, дуслар!








## ТАТАРСТАННЫҢ НӘНИ ПРИНЦЕССАЛАРЫ БИЛГЕЛЕ БУЛДЫ!

**2016 елның 12 июнендә «ТАТАРСТАННЫҢ НӘНИ ПРИНЦЕССАЛАРЫ 2016» («МАЛЕНЬКИЕ ПРИНЦЕССЫ ТАТАРСТАНА 2016») дип аталучы сигезенче республика балалар фестивале узды.**

Фестивальдә Татарстанның төрле шәһәрләреннән 5 яшьтән 14 яшькә кадәр 19 кыз катнашты.

Бәйгенең төп идеясе – балалар иҗатын үстерү, популярлаштыру, сәләтле балаларның иҗади мөмкинлекләрен ачу, әти-әниләрнең һәм балаларның уртак эшчәнлеген берләштерү, киләчәк буынны җәмгыятьнең мәдәни традицияләре белән таныштыру, игелекле эшләргә тарту.

Финалга әзерлек вакытында катнашучылар һәм аларның гаиләләре олы яшьтәгеләргә һәм балаларга ярдәм итү, әйләнә-тирәне һәм сулыкларны саклауга юнәлтелгән хәйрия акцияләре үткәрделәр.

«МаленькиеПринцессыТатарстана»ИҗтимагыйоешмасыПрезидентыНаталья Киселева сүзләренә караганда, фестивальнең иң талантлы катнашучылары инде быел ук Татарстан Республикасын дөньяның төрле илләрендә булачак зур һәм мәртәбәле халыкара балалар проектларында тәкъдим итәчәк.

Кызлар Принцессалар булып үсеннәр, ә Принцессалар Королеваларга әйләнсен!




**№7 (316) – 2016**

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит с марта 1990 года.

Директор
**Зиннур ХӨСНИЯР (Зиннур Зыятдин улы ХӨСНЕТДИНОВ)**

Баш мөхәррир
**Зилә ЯЗ (Зилә Зиннур кызы ХӨСНЕТДИНОВА)**

Баш мөхәррир урынбасары
**Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА**

Мөхәррирләр
**Гөлназ ЯРМИЕВА**
**Алсу НИЗАМИЕВА**

Баш рәссам
**Әлфия ЙОСЫПОВА**

Компьютер дизайны
**Мөнирә КУЗИЕВА**

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

Басарга кул куелды 28.06.16 ел.
Кәгазь форматы 60x90 1/8.
Гарнитура – PT Sans.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-1618. Тираж: 8500 данә.
Килгән хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал өегезгә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.



Журналны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Бәясе ирекле. Индекс: П2339.

Тышлыкта Әлфия Йосыпова рәсеме.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 519-45-89.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.

# Язып һәм телевизор от!

**1 Языл**
30.06.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

**2 Җибәр**
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

**3 От**
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!




**БҮЛӘКЛӘР УЙНАТУ**

**2016 елның 19 августы**






Акцияне үткәрү вакыты:18.04.2016 - 20.09.2016

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама